**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**07 июнь, 2023 ел** **№ 299**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Генераль планын раслау турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 1 өлеше 20 пункты, 14 статьясының 3 өлеше нигезендә, 31.03.2023-01.04.2023 ел гавами тыңлаулары беркетмәләрен, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең генераль планын раслау проекты буенча 2023 елның 07 апрелендәге гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планын кушымта нигезендә расларга.
2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына Федераль дәүләт территориаль планлаштыру мәгълүмат системасының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Генераль планын урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Биектау муниципаль районы Советы тарафыннан расланган 2022 елның 16 маендагы 169 номерлы карарны үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru, һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлеге, законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф. Хисамутдинов

Биектау авыл җирлеге Генераль планы проекты материаллары белән ФГИС ТП